«Раслыйм»:
Яр Чаллы шәһәре мэры
Магдеев Наил Гамбәр улы
___________________________
«_____»_____________2022ел

«Раслыйм»
ТР МДН мөфтие
Камил хәзрәт Сәмигуллин
___________________________
«_____»_____________2022 ел

# НИГЕЗЛӘМӘ

## Идел буе Болгар дәүләтендә исламны кабул итүнең 1100 еллыгы кубогына мөселманнарның татар милли көрәше һәм кул көрәше буенча берләштерелгән Рәсәйкүләм турниры

### 1. Максат һәм бурычлар:

- татар халкының милли спорт төрләрен һәм традицияләрен актив тормыш рәвешенә кертү;
- мөселманнар арасында татар милли көрәшен һәм кул көрәшен киң җәелдерү һәм үзара дуслык җепләрен тагын да ныгыту;
- мөселманнарда сәламәт яшәү, чыдамлык, түземлек сыйфатларын тәрбияләү өчен шартлар тудыру.

### 2. Бәйгене үткәрү вакыты һәм урыны:

- бәйге Яр Чаллы шәһәренең МАУ «СШОР «Витязь» М.С. Бибишев исем.» спорткомплексында 2022 елның 26 мартында уздырыла (адресы: Яр Чаллы проспекты, 23 йорт, «Челныгорстрой» тукталышы. Телефоны: 8(8552) 56-65-99).

Шәхси-команда ярышлары олимпия системасы буенча үткәрелә:

- иртәнге сәгать 8 дән 9 га кадәр – катнашучыларны үлчәү;
- сәгать 9 дан 9.30 га кадәр – вәкилләр һәм хөкемдарлар җыелышы;
- сәгать 10.00 да – бәйгене ачу.

### 3. Бәйгенең җитәкчелеге:

- бәйгеләрне әзерләүче һәм уздыручы гомумҗитәкчелек – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте, Чаллы шәһәре башкарма комитеты, Россия көрәш Федерациясе, Татарстан Республикасы көрәш Федерациясе һәм Чаллы шәһәре мөхтәсибәте.
- төп хөкемдар – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәтенең баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев.
- турыдан-туры җитәкчелек вазыйфасы Чаллы мөхтәсибәте һәм хөкемдарлар коллегиясенә йөкләнелә.

### 4. Бәйгедә катнашучылар һәм бәйгеләрне уздыру шартлары:

- бәйгеләрдә 18 яшьтән кече булмаган, ***намаз укучы***, тиешле физик әзерлеккә һәм медицина рөхсәтенә ия мөселманнар гына катнаша ала;

- көрәш буенча авырлык категорияләре: 65; 75;. 85; 95; 105 һәм 105 килограммнан артык;

- кул көрәше буенча авырлык категорияләре: 65 килограммга кадәр, 85; 85 килограммнан артык;

- үлчәнгәнгә кадәр, ***катнашучылар намаз уку кагыйдәләрен белү буенча тест үтәргә тиеш;***

- бәйгедә катнашучыларның үзләре белән паспорт, ИНН, СНИЛС булырга тиеш;

- ***бәйгеләр җирәбә тәртибе буенча уздырыла;***

- бәйгедә катнашучылар барысы да көрәшкә кагылышлы спорт киеменнән һәм түбәтәйдән булырга тиеш.

- бәйгедә катнашучылар һәм судьялар битлек режимын үтәргә тиеш.

**5. Бүләкләү:**

- һәр авырлык категориясе җиңүчеләренә диплом һәм кыйммәтле бүләк тапшырыла;

- җиңүче командага Кубок бирелә;

- ***үз авырлык категориясендә беренче урын яулаганнар арасында җирәбә салына, отучыга турнирның төп бүләге –Хаҗга юллама тапшырыла.***

**6. Финанс чыгымнары:**

- турнирны әзерләү һәм уздыру, җиңүчеләрне бүләкләү өчен тотылган бар чыгымнарны бәйгене оештыручылар хәл итә;

- бәйгедә катнашучы спортчыларның, хөкемдарларның, тренерларның чыгымнарын (юл хакы, туклану, яшәү урыны) аларны командировкага юллаучы оешмалар түли.

**7. Гаризалар:**

- командировкага җибәрүче оешма һәм табиб тарафыннан расланган гаризалар 2022 елның 15 мартына кадәр хөкемдарлар коллегиясенә тапшырыла;

- бәйгедә катнашучы һәркемнең бәхетсезлек очракларыннан страховка кәгазе булырга тиеш;

- үлчәнер алдыннан һәр катнашучы үзенең паспортын күрсәтергә тиеш.